РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 28 » 12 2024 ел №1241

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы территориясендә
торак хезмәтләре күрсәткән өчен түләү
күләмен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы «Күпфатирлы йортта гомуми милекне тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта гомуми милекне тиешле дәрәҗәдә сыйфатлы түгел итеп һәм (яки) билгеләнгән вакыттан артып киткән тоткарлыклар белән идарә итү, тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм башкару очрагында торак бинаны тоту өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 491 санлы карары, Россия Төзелеш Министрлыгының 06.04.2018 № 213/пр «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннары хуҗалары өчен торак урынын тоту өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик киңәшләрне раслау турында, торак урынын тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү 0буенча карар турында» боерыгы, Татарстан Республикасының 28.07.2004 № 45-ТРЗ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар итте:

1. 2025 елның 1 гыйнварыннан социаль наем шартнамәләре, муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен һәм күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында Карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен һәм гомуми җыелышта торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы торак йорттагы урыннар милекчеләре өчен, торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен 2025 елга әлеге карарга кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/адресы буенча бастырырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Рәсми Татарстан» мәгълүматтелекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Габдрахманова Г.Г.
2-42-06

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Башкарма
комитеты карарына кушымта
______________ 2024 ел № ________

**Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен, күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен һәм гомуми җыелышта 2025 елга түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләме**

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Үлчәү берәмлеге** | **2025 елга тариф (01.01.2025 - 30.06.2025 ел)** | **2025 елга тариф (01.07.2025 - 31.12.2025 ел)** |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Торак фонд белән идарә итү | руб./$м^2$ | 1,81 | 1,94 |
| Йорт яны территориясен җыештыру | руб./$м^2$ | 2,17 | 2,32 |
| Торак бинаны агымдагы ремонтлау | руб./$м^2$ | 4,16 | 4,46 |
| Йорт эчендәге инженерлык челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту: | | | |
| сууткәргеч-канализация челтәрләре | руб./$м^2$ | 2,66 | 2,85 |
| газ белән тәэмин итүнең фасад һәм йорт эчендәге челтәрләре | руб./$м^2$ | 0,41 | 0,44 |
| электр белән тәэмин итү челтәрләре | руб./$м^2$ | 1,50 | 1,61 |